ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 ноября 2019 г. № 5900

Башкарма комитетның 2018 елның 20 ноябрендәге 6827 нче карары белән расланган 2019, 2020, 2021 елларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы муниципаль планына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның Кыска вакытлы муниципаль планын актуальләштерү максатында, Россия Федерациясе Торак кодексының 168 маддәсенең 7, 8 бүлекләренә, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүне оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ санлы Законының 10 маддәсенең 11 бүлегенә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планнарын раслау тәртибен билгеләү турында» 2017 елның 20 мартындагы 155 нче карарына, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24, 5.25 пунктларына туры китереп, күп фатирлы йортлардагы торак милекчеләренең гомуми җыелышларының беркетмәләре нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2018 елның 20 ноябрендәге 6827 нче карары белән расланган 2019, 2020, 2021 елларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 нчы карары белән расланган

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның Кыска вакытлы муниципаль планына (Башкарма комитетның 2019 елның 29 мартындагы 1627 нче карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 нче «Күп фатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрү күләмнәре» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Күп фатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрү күләмнәре

Әлеге Кыска вакытлы муниципаль планны тормышка ашыру гомуми мәйданы 5 782 133,18 кв. метр булган 475 күп фатирлы йортта 225 259 гражданның уңай һәм куркынычсыз яшәү шартларын тәэмин итүне күздә тота.

| Т/с | Күп фатирлы йортта капиталь ремонт үткәрүнең эш төрләре | Үлчәү берәмлеге | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Күләме | Күләме | Күләме |
| 1 | Йорт эчендә җылылык белән тәэмин итүнең инженерлык системасын ремонтлау | метр | 111 319,1 | 51 847,2 | 100792,3 |
| 2 | Йорт эчендә кайнар су белән тәэмин итүнең инженерлык системасын ремонтлау | метр | 93 687,2 | 116 209,5 | 64686,7 |
| 3 | Йорт эчендә салкын су белән тәэмин итүнең инженерлык системасын ремонтлау | метр | 47 481,1 | 60574,00 | 55408 |
| 4 | Йорт эчендә су бирүнең инженерлык системасын ремонтлау | метр | 36 877,6 | 36814,30 | 58251,5 |
| 5 | Йорт эчендә электр белән тәэмин итүнең инженерлык системасын ремонтлау | кв.м. | 30 558,3 | 30 687,70 | 62009,5 |
| 6 | Исәпләү приборларын, җайга салу узелларын урнаштыру | данә | 0 | 0 | 0 |
| 7 | Подвалны ремонтлау | кв.м. | 4 090 | 3 045,00 | 5866,8 |
| 8 | Түбәләрне ремонтлау | кв.м. | 62372,8 | 43 721,32 | 88812,4 |
| 9 | Лифт җиһазларын ремонтлау/алмаштыру | данә | 140 | 96 | 26 |
| 10 | Фасадны ремонтлау | кв.м. | 214902,03 | 217 800,26 | 187479,2 |
| 11 | Янгынга каршы автоматика һәм төтен бетерү системаларын урнаштыру | кв.м. | 0 | 35 183,00 | 11748,4 |
| 12 | Подъездларны ремонтлау | кв.м. | 62 353,3 | 0 | 0 |
| 13 | Техник паспортлар ясау | данә | 96 | 148 | 61 |
| 14 | ИТП урнаштыру | данә | 0 | 146 | 0 |
| 15 | Фундаментны ныгыту | кв.м. | 955,9 | 0 | 0 |

Кыска вакытлы муниципаль планга кертелгән ремонт төрләре буенча күп фатирлы йортлар реестры аңа 1-9 нчы кушымталарда күрсәтелгән.»

2) 3 нче «Ресурс белән тәэмин итү» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Ресурс белән тәэмин итү

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, шәһәр бюджеты финанславы, торак милекчеләре ширкәтләре, торак кооперативлары, торак төзелеше кооперативларының яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларының яисә күп фатирлы йорттагы торак милекчеләренең акчалары

Кыска вакытлы муниципаль планны финанслау чыганаклары булып тора.

Кыска вакытлы муниципаль план чараларын финанслауның гомуми күләме 3 858 865 859,23 сумны тәшкил итәчәк, шул исәптән:

- Татарстан Республикасы бюджетыннан – 882 294 976,93 сум;
- шәһәр бюджетыннан – 802 041 000 сум;
- торак милекчеләре ширкәтләре, торак кооперативлары, торак төзелеше кооперативлары әгъзаларыннан яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларыннан яисә күп фатирлы йортлардагы торак милекчеләреннән – 2 174 529 882,30 сум.

| Финанслау чыганаклары | Финанс средстволары, барлыгы, сум | | |
|---|---|---|---|
| | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчалары | 319 053 054,93 | 281 620 961,00 | 281 620 961,00 |
| Шәһәр бюджеты акчалары | 267 347 000,00 | 267 347 000,00 | 267 347 000,00 |
| Торак милекчеләре ширкәтләре, торак кооперативлары, торак төзелеше кооперативлары яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларыннан яисә күп фатирлы йортлардагы торак милекчеләре акчалары | 707 583 618,48 | 822 644 877,92 | 644 301 385,90 |
| Барлыгы | 1 293 983 673,41 | 1 371 612 838,92 | 1 193 269 346,90 |

Күп фатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрүгә финанс средстволарының күләме

| Т/с | Күп фатирлы йортта капиталь ремонт үткәрүнең эш төрләре | Финанслауга ихтыяҗ, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| 1 | Проект-смета документларын эшләү һәм экспертизалау | 26 929 090,06 | 38 981 288,92 | 33 398 889,17 |
| 2 | Техник күзәтчелек | 12 045 916,47 | 12 969 524,29 | 11 412 703,91 |
| 3 | Йорт эчендә җылылык белән тәэмин итүнең инженерлык системасын ремонтлау | 178 602 459,9 | 91 141 626,5 | 167 583 162,7 |
| 4 | Йорт эчендә кайнар су белән тәэмин итүнең инженерлык системасын ремонтлау | 107 807 592,78 | 169 319 503, 71 | 128 748 998,36 |
| 5 | Йорт эчендә салкын су белән тәэмин итүнең инженерлык системасын ремонтлау | 60 447 866,72 | 77 902 220,52 | 108 188 209,39 |
| 6 | Йорт эчендә су бирүнең инженерлык | 64 764 984,25 | 71 430 693,57 | 103 873 930,69 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | системасын ремонтлау | | | |
| 7 | Йорт эчендә электр белән тәэмин итүнең инженерлык системасын ремонтлау | 37 239 885,67 | 27 024 848,96 | 65 443 047,26 |
| 8 | Исәпләү приборларын, җайга салу узелларын урнаштыру | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 9 | Подвалны ремонтлау | 3 701 947,94 | 928 725,00 | 3 385 208 |
| 10 | Түбәләрне ремонтлау | 106 316 665,54 | 89 501 579,07 | 168 172 900,19 |
| 11 | Лифт җиһазларын ремонтлау/алмаштыру | 299 049 118,17 | 214 795 914,5 | 61 421 341,33 |
| 12 | Фасадны ремонтлау | 345 309,093 | 440 592 505,57 | 321 293 593,87 |
| 13 | Янгынга каршы автоматика һәм төтен бетерү системаларын урнаштыру | 0,00 | 10 469 287,67 | 12 500 000,00 |
| 14 | ИТП урнаштыру | 0,00 | 107 345 525,6 | 0,00 |
| 15 | Подъездларны ремонтлау | 34 898 198,65 | 0,00 | 0,00 |
| 16 | Фундаментны ныгыту | 1 949 491,49 | 0,00 | 0,00 |
| 17 | Техник паспортлар ясау | 14 921 362,35 | 19 209 595,04 | 7 847 362,03 |
| | Барлыгы | 1 293 983 673,41 | 1 371 612 838,92 | 1 193 269 346,90 |

Капиталь ремонт үткәрүнең бәясе күрсәтелгән эш төрләре буенча күп фатирлы йортлар исемлеге Кыска вакытлы муниципаль планга 1-9 нчы кушымталарда күрсәтелгән»;

3) 1-9 нчы кушымталарны әлеге карарга 1-9 нчы кушымталарда каралган редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны, шулай ук «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенә әлеге карарны рәсми басылып чыккан көннән башлап 15 көн эчендә «Интернет» челтәрендә торак-коммуналь хуҗалыгының дәүләт мәгълүмат системасы сайтында www.dom.gosuslugi.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы — И.С. Зуев

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ